| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.02.2025 № 183

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2024 елның 01 августындагы 872 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2024 елның 01 августындагы 872 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 22 августындагы 965 номерлы, 2025 елның 04 февралендәге 118 номерлы, 2025 елның 11 февралендәге 160 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына һәм чит ил гражданнарына күрсәтелгән карар белән расланган бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибендә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләме – 150 000,00 (йөз илле мең) сум.»;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Контракт төзегән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган түләү 01.02.2025 елдан 31.12.2025 елга кадәрге чорда башкарыла.».

1.2. Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына һәм чит ил гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләүне билгеләү буенча комиссия турында күрсәтелгән карар белән расланган Нигезләмәдә:

1 пунктта «2024 елның 01 августыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2025 елның 01 февраленнән 2025 елның 31 декабренә кадәр" сүзләренә алмаштырырга.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карар редакциясендәге нигезләмәләрнең гамәлләре 2025 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин